*СӘМИГА СӘҮБАНОВА*

# Болытның Койрыгы Кайда?



Казан
Татарстан китап нәшрияты
2003

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат)–4
С 93

Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен

Рәссам *Елена Ермолина*



**Сәүбанова Сәмига**

С 93 Болытның койрыгы кайда?: Әкиятләр.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.— 54 б., рәс.белән.

ISBN 5-298-01334-1

©Татарстан китап нәшрияты, 2003

## *КУЯН КҮЧТӘНӘЧЕ*

Аучы куянауларга дип урманга килгән. Куянны күргән дә аңа мылтык төбәгән:

— Куян, хәзер мин сине атам! — дигән.

Ә куян бик тәмләп кишер кимерә икән.

— Качсам, аучы мине күзен дә йоммыйча шунда ук атып үтерәчәк,— дип уйлаган ул.— Ичмасам, туйганчы ашап калыйм.

— Башта кишеремне ашап бетерим инде,— дигән ул аучыга.— Аннан атарсың.

— Кишерең күпме соң? — дип сораган аучы.

— Әллә ни күп түгел, менә алдымдагы өемдә генә,— дигән куян.

— Ярар, аша,— дигән аучы.— Мин көтәм.

Аучы куянның тәмләп кишер кимергәнен көтеп утыра башлаган.

Куян кишерне бик озак кимергән. Үзе эченнән генә:

— Озаграк кимерсәм, гомерем дә озая, озаграк кимерим, озаграк кимерим,— дип уйлый икән.

Утыра торгач, аучының да кишердән авыз итеп карыйсы килгән.

— Куян дус! Үзең генә кимермә, миңа да ыргыт әле,— дигән.

Куян аңа:

— Әйдә, мин кишернең бер башыннан, син икенче башыннан кимер,— дигән.

— Ярар, алайса,— дигән аучы һәм кишернең икенче башын авызына кабып кимерә башлаган. Кишер чынлап та бик тәмле булган, куянны ауларга килгәнен дә онытып җибәргән.

Берзаман нигә килгәнлеге исенә төшсә — куяннан җилләр искән!

Аучы ары караган, бире караган, бер өем кишердән башка берни дә тапмаган.

— Үзе булмаса, күчтәнәче дә ярап торыр,— дигән аучы һәм кишерне капчыгына салып, өенә алып кайткан.

Өендә карчыгы:

— Кая куяның? — дип каршы алган.

— Куян үзе кайта алмады, аның каравы күчтәнәч җибәрде,— дигән аучы.

— Бик шәп булды әле,— дигән карчыгы.— Ничек итеп куянны кызганмыйча казанга салып пешерермен, дип кайгырып утыра идем. Хәзер кишер бәлеше пешерәм.

Карчык кишерне турап, аңардан зур бәлеш пешергән. Үзләре дә ашаган, күршеләрен дә сыйлаган, хәтта куянның үзенә дә илткәннәр.



# ӘЛЕ ЯРЫЙ, АЙНЫ ТИШМӘДЕ

Шулай беркөнне Төлке белән Саескан аптырашып утыралар икән.

— Заманалар үзгәрде. Кайсы бала чыгара, кайсы бала очырта, кайсы, комсызлана-комсызлана, оясына ризык ташый. Авызларына су тутырганнармыни. Яннарына килсәң, бер авыз сүз алып булмый. Нәрсә булган боларга? — дигән Саескан.

Төлке дә:

— Минем дә хәлләр начар. Борчасына хәтле ташлап әллә кая качты. Тунымны чистартырга ярап куялар иде. Кайсының янына барсам, шунысы: «Кеше эшләгәндә эч пошыртып йөрмә!» — дип кенә җибәрә. Барысы бергә сүз куешканнармыни. Бик алдыйсы килеп тора иде аларны! — дигән.

— Алар гына дөнья тоткасы дип белерсең!

— Алардан башка яши алмабызмы әллә?

— Әйе шул. Бик әйбәт итеп яшәр идек тә, бүтән җир юк шул. Беләсеңме нәрсә? Безнең Керпенең энәләре тылсымлы бит! — дигән Саескан.

Төлкенең күзләре ялт-йолт килгән.

— Тылсымлы? Ничек инде тылсымлы? — дигән ул.

— Әйе шул, тылсымлы. Тик бу турыда берәү дә, шул исәптән Керпе үзе дә белми. Беләсеңме, аның энәсен җиргә төртсәң, ул урында биек тау барлыкка килә.

Төлкенең ышанасы килмәгән.

— Юктыр ла! Син миннән дә уздырып җибәрәсең,— дигән ул.

— Чы-ын менә! Моны миңа әбием әйтте. Ә әбиемә — әбиемнең әбисе әйткән. Ә әбиемнең әбисенә...

— Нишләрбез соң без ул тау белән?

— Мин тау башына оя корам. Син дә шунда яшәрсең, балалар үстерерсең. Мин тау башыннан тирә-якта нәрсә бар, шуны күзәтермен. Беләсеңме, тау башыннан кара-

ганда, еракта-еракта яшеренгән Куян баласына хәтле уч төбендәгедәй күренә,— дигән Саескан.

Төлкенең моны тизрәк күрәсе килгән.

— Әйдә, Керпедән энә алыйк,— дигән ул.

Керпедән энә сораганнар. Керпе исә аны-моны уйлап тормаган, энәсен йолыккан һәм аларга биргән. Бер энәдән аның энәләре һич тә кимемәгән.

Энәне җиргә төртүләре булган, шундый биек тау күтәрелгән.

Саескан, Төлке, Керпе тау башында ук калганнар. Керпенең тау башында яшисе килмәгән, шунда ук туп булып йомарланган да аска тәгәрәгән.

Тау исә үсә торгач, болытларга җиткән, аларны үткән, айга килеп төртелгән.

Айның мондый әрсез тауны бер дә күргәне булмаган.

— Үсүдән туктамасаң, үзеңне һәм төлке белән саесканны мәңге эреми торган бозга әйләндерәм! — дигән.

Төлке белән Саесканның бозга әйләнәсе килмәгән.

— Тукта, үсүдән тукта! Зинһар, безне харап итмә! Тылсымлы дигәч тә бу хәтле борын чөяргә димәгән бит! — диешкәннәр алар.

Тик алар ялынганга карап тау үсүдән туктамаган. Шуннан соң Саескан тау башында тырпаеп торган энәне тартып алган. Тау шул арада юкка чыккан. Төлке, Саескан, һавада мәтәлчек атына-атына, аска очканнар.

Бик озак өнсез ятканнар болар. Шуннан соң әкрен генә башларын калкытканнар.

— Әле ярый, керпе энәсе айны тишмәде,— дип куанышканнар, ди.





## *АЮ БАЛАСЫ БЕЛӘН КЕРПЕ*

Аю баласы үзенең әнисен югалткан. Югалткан дип, оя тирәсеннән ерак та китмәгән булган ул. Бары тик әнисе бал эзләгән җирендә озаграк кына тоткарланган.

Аю баласы бармагын суырып караган, тик тамагы туймаган. Колагын кашып караган, алай да ашыйсы килүе басылмаган.

Шуннан киткән бу әнисен юллап. Каршысына керпе очраган.

— Кая барасың? — дигән керпе.

— Әниемне югалттым,— дигән аю баласы.

— Син ояңнан ерак китмә, югыйсә адашырсың. Әниең менә, күрерсең, озакламый кайтыр. Ул кайтканчы мин әниең булып үзем торам.

Акыллы керпе булган ул, әниләреннән адашып күпме җәнлек балаларының харап булуын күп күргән.

— Ярар алайса, әнием бул,— дигән аю баласы.

Шулай итеп, керпе әни булган.

Аю баласы керпегә сыенмакчы булган, тик энәләренә кадалган.

— Минем әнием энәле түгел иде бит,— дип аптыраган ул.

— Ярар алайса, син минем әни бул, ә мин синең улың булырмын,— дигән керпе.

Аю баласы риза булган. Әнисе үзен иркәләгән кебек, керпене иркәләмәкче булган, тик тагын энәгә кадалган.

— Мин үзем дә энәле түгел бит,— дип аптыраган аю баласы.

Ул арада әнисе кайткан. Ул улын да, керпене дә бал белән сыйлаган.

# *ТАТЛЫ ҖӘЙМӘ*

Бер күл буенда үрдәкләр, ә күл эчендә бака-бакылдык яшәгән. Бака яшел ефәк җәймә үргән, үрдәкләр камышлыкта оя ясап, йомырка салганнар, бәбкә чыгарганнар.

— Җәймәм шундый матур булсын, күл өсләрен тутырсын! — дигән бака.

Су буена төшкән каз бәбкәләре дә, камышлыктагы үрдәкләр дә җәймәне чемченергә яратканнар.

— Нинди ямьле җәймә!

— Нинди татлы җәймә! — диешкәннәр алар.

— Ошаса, теләгән хәтле ашагыз. Мин тагын да матуррак җәймә үрергә тырышырмын! — дигән бака.

— Бак-бак-бак! Бак-бак-бак!
Ефәк кебек затлы җәймәм,
Күрәсең килсә — килеп бак!
Ашыйсың килсә — татып бак!
Бак-бак-бак! Бак-бак-бак! —

дип җырлаган ул җәймә үргәндә.

Ефәк кебек хәтфә җәймә турындагы хәбәр тирә-якларга таралган. Җылы якларга кыш чыгарга киткән үрдәкләр тараткан бу хәбәрне. Алар диңгез балыкларына сөйләгәннәр. Диңгез балыкларының да үзе тәмле, үзе йомшак, үзе матур, үзе ефәк җәймәне тотып та, татып та карыйсылары килгән.

— Үзегез генә сыйланмагыз, безгә дә алып килегез,— дигәннәр алар.

— Икенче килгәндә, күпме күтәрә алабыз, шулхәтле алып килербез,— диешкәннәр үрдәкләр.

Икенче көзне һәркайсы үзе белән берәр кисәк ятьмә алып килеп, диңгез өстенә салган. Диңгез өсте тоташ яшел җәймә белән капланган.

Җәймә балыкларга бик ошаган.

— Үзе йомшак, үзе нәфис, үзе тәмле! — диешкәннәр

алар, җәймәне ашап бетерә язганнар. Бер кечкенә кисәк калгач кына туктаганнар болар.

— Болай булмый, мондый җәймәне үзебезгә үрергә кирәк! — дигәннәр алар.

Һәм һәр балык җәймә үргән. Диңгез өстендә тагын шундый тәмле, татлы, ямьле җәймәләр барлыкка килгән. Балыклар кирәк чагында җәймәләр астына яшеренгәннәр, кирәк чагында ашаганнар. Хәзер вак балыкларга куркыныч килгәндә яшеренергә бик әйбәт урын да булган ул.

Моны күргәч, үрдәкләр:

— Әйдәгез, җир өстенә дә җәймә җәябез! — дигәннәр.

Шулай итеп, бер бака-бакылдык аркасында җир өстен дә яшел җәймә каплап алган. Ул җәймә тора-бара урманнарга, болыннарга, куаклыкларга әйләнгән. Яшел урманнар, болыннар, куаклыклар арасында төрле төстәге гөлләр үсеп чыккан һәм җир йөзе гаҗәеп матур төскә кергән.

Бака-бакылдык хәзер дә җәймә үрә һәм эшләп арыгач, кичләрен үзенчә мактана икән, ди:

Бак-бак-бак! Бак-бак-бак!
Ефәк кебек хәтфә җәймәм,
Күрәсең килсә — килеп бак!
Ашыйсың килсә — татып бак!
Бак-бак-бак! Бак-бак-бак!





# САБАК

Булган, ди, бер чәчәк. Сабагында чайкалып утырган-утырган да, әйтеп куйган бу:

— Җил мине төрле якка селкетә, кояш кыздыра, ул кыздырганда күләгәгә дә кереп яшеренеп булмый, туйдым бу сабакта гына утырудан,— дигән.

Бүтәннәр аның белән бәхәсләшмәгәннәр. Аларга сабакта утыру да, җил искәндә чайкалу да, кояшка карап утыру да, кичке җиләс һавада таҗларын йомып, йокыга талу да бик рәхәт булган.

Шул арада болынга бер кыз йөгереп килгән дә әлеге чәчәкне өзеп түшенә кадаган.

Чәчәк куанычыннан нишләргә дә белмәгән.

— Күрдегезме, мин хәзер барыгыздан да өстәрәк, биектәрәк, мин кояшка да, җилгә дә якынрак, хәзер мин аларның үзләренең кирәгеннән бирәм! — дигән.

Тик җилне туктата, кояшны суыта алмаган, үзе генә сулган. Кызның түшеннән чүп үләннәре арасына төшеп калган, җил очыртып алып киткән дә кире болынга илтеп ташлаган.

Чәчәкнең күзләреннән яшьләр тамган. Сабагына кире кайтып утырыр иде дә, соң булган шул. Бүтән гөлләр аңардан көлгәннәр.

— Кояш һәм җил белән кем көрәшә соң? — дигәннәр алар.— Кояш белән җил булмаса, без беребез дә үсмәс идек. Җил безнең орлыкларны тирә-якка тарата, кояш безнең таҗларыбызны кирәк чагында ачтыра, кирәк чагында — йомдыра.

Кояш та, җил дә бу тиле чәчәкне ачуланмаганнар. Җир аны үз кочагына алган, җил яңгыр чакырган. Яңгыр явып үткәч, бер генә түгел, әллә ничаклы чәчәк үсеп чыккан. Әлеге чәчәкнең орлыкларыннан үсеп чыкканнар алар.

## *КАР БАБАЙ КАЯ КИТКӘН?*

Алсу белән Марат Кар бабай ясарга булганнар. Кар тәгәрәтә башлаганнар. Тик күпме тәгәрәтсәләр дә, карябышмый, тарала да китә, ди. Шуннан соң Алсу елап җибәргән. Кар бабай ясыйсы бик тә килгән шул аның.

Марат әйткән:

— Ярар, Кар бабай үзем булам! — дигән.

Алсу куанычыннан кулларын чәбәкләгән.

Марат баскан, Алсу аның кулына себерке тоттырган, башына чиләк кидергән һәм куанычыннан җырлый-җырлый бии башлаган.

Кар бабай, Кар бабай
Безне бик ярата...
Ул безгә Яңа ел
Бүләге тарата...

— Кар бабай! Минем Кар бабаем бар! — дигән һәм Кар бабай тирәсендә әйләнеп йөри башлаган. Аңа ишегалдына чана шуарга чыккан бүтән балалар да кушылган. Кар бабай аларга да бик ошаган.

Маратның да Кар бабай тирәсендә биисе килгән. Балаларга ул да кушылган.

Җырлап-биеп арыгач, карасалар, Кар бабайдан җилләр искән. Иске чиләге белән себеркесе генә аунап калган.

Ары караганнар, бире караганнар, шуннан соң аптырап кулларын җәйгәннәр.

— Кая китте соң шул арада? — дип аптырашканнар.

Чынлап та, кая киткән икән ул?

## *ШУК ЙОМГАК*

Булган, ди, бер песи баласы. Исеме булган Шомырт. Шомырт бик шук булган, уйнарга яраткан. Ул аеруча хуҗабикә җеп эрләгәндә аны күзәтеп утырырга һәм аның эрләгән җепне йомгакка ураганын карап торырга яраткан.

Хуҗабикә җеп тартканда кайчагында җырлый икән:

Бер тартам — бер орчык,
Ике тартам — ике орчык.
Орчык-орчык җеп тартам да
Йомгак-йомгак җеп урыйм.

Ә моңа каршы песи баласы Шомырт:

Йомгак-йомгак җеп урагач,
Тәгәрәтеп мин уйныйм,—

дип мырлый икән.

Шулай хуҗабикә җепне урый да, йомгагын өстәлгә куеп, чыгып китә икән. Песи баласы аның чыгып китүен генә көтеп тора да йомгакны тәгәрәтеп уйный башлый икән.

— Тәгәрә-тәгәрә йомгагым,
Үзем кебек йомшагым.
Уйныйк әйдә икәүләп,
Сикереп йә мукәйләп,—

ди икән.

Ә беркөнне Шомырт кызыбрак уйнап киткән һәм йомгак тәгәри-тәгәри торгач, сүтелеп тә беткән. Песи баласы бик аптыраган. Йомгакны эзләгән, тик йомгак урынына чуалып беткән җептән башка берни дә тапмаган. Ә хуҗабикә кулына бәйләм энәләре тотып керсә — йомгактан җилләр искән. Ул да аптыраган:

— Шомырт, синең эшеңме бу? — дип сораган.

— Мыр-мыр-мыр... Мин белмим... Мин йомгакның кая киткәнен күрмәдем...— дигән Шомырт.



Хуҗабикә чуалган җепне кабат йомгакка ураган да шкаф өстенә үк куйган. Йомгакны кабат күргәч, песи баласының күзләре ут булып яна башлаган. Ул шкаф өстенә менгән дә йомгакны тәгәрәтә, сикертә башлаган. Йомгак люстрага менгән, песи баласы аның артыннан, йомгак люстрадан идәнгә сикереп төшкән, песи баласы аның артыннан сикермәкче булып, аска караган икән, куркып кычкырып җибәргән.

Ә йомгак аны:

— Куркак! Куркак! Куркак! Менә хәзер тотып кара инде үземне! — дип, үртәп сикерә дә сикерә икән.

— Үртәмә инде, зинһар, төшәргә булыш! — дип ялынган Шомырт.

Йомгак аның янына сикереп менгән, песи баласы аңа тотынган һәм кире икәүләп идәнгә сикергәннәр. Хуҗабикә йомгагын алыйм дип керсә, йомгак сикерә дә сикерә икән.

— Бигрәк шук йомгак булдың әле син,— дигән ул.— Синнән бияләй бәйләсәм, кулымда тормассың, оекбаш бәйләсәм, мине сикертеп алҗытырсың. Юк, мин синнән оекбаш та, бияләй дә бәйләмим. Песиемнең күңелен күр, аның белән уйна, менә булыр синең эш.

Хуҗабикә шулай дигән дә әлеге йомгакны бөтенләйгә Шомыртка биргән. Шомырт, билгеле, сөенгән. Сөенеченнән люстрага, люстрадан идәнгә сикергән. Йомгак та аның белән сикергән. Сикерә торгач, түп-түгәрәк тупка әйләнгән.



# *АКЫЛЛЫ КУЯН*

Төлке белән эт урманда очрашканнар. Эт тук, матур, йоннары елкылдап тора, төлкенең эче эчкә ябышкан, кабыргалары беленеп тора икән.

Төлке әйткән:

— Шундый матур булуыңның серен әйт әле,— дигән.

Аңа каршы эт:

— Минем хуҗам бар. Ул мине ашата, эчертә, җылы ояда йоклата, мин шуның өчен турылыклы хезмәт итәм, ул мине берәүдән дә курыкмаска, батыр булырга өйрәтә,— дигән.

Төлке эткә бик кызыккан. Аның да хуҗалы буласы килгән. Киткән бу шулай урман буйлап, үзенә хуҗа эзләп. Бара торгач, каршысына аю очраган.

— Аю абзый, минем хуҗам бул,— дигән.

Аю риза булган.

Яши болар икәүләп. Бергәләп ауга йөриләр, бергәләп ашыйлар, бергәләп йоклыйлар, ди.

Шулай итеп җәй үтеп киткән. Аю кышкы йокыга әзерләнә башлаган. Төлке дә йокларга әзерләнә башлаган. Икесенә зур түшәк түшәгәннәр, зур юрган әзерләгәннәр. Төлке аюның кочагына кереп яткан. Аю яту белән рәхәтләнеп гырлый-гырлый йоклап киткән. Төлке төнлә йоклый, көндез һич кенә дә йоклый алмый икән. Шулай берничә көн түзгән бу. Аюга рәхәт, тәпиен авызына капкан да, йокы аралаш шуны кәнфит урынына суыра икән. Аңа карап төлке дә тәпиен суырып караган, ашыйсы килүе басылмаган. Аптырагач, аюның корсагын ялап караган, тамагы туймаган.

Төлке аюны калдырып, тамак ялгарга ни дә булса табып булмасмы, дип, тагын урман буйлап киткән. Кишер кимереп утырган куянны очраткан. Төлке куянны тотып ашамакчы булган, тик куян аның маңгаена кишер ыргыткан, төлке авырткан маңгаен уган арада, куян әллә кая качып котылган.

Төлке аптырагач, кишерне кимермәкче булган, әмма бер тәмен дә тапмаган. Шуннан соң кишерне алган да:

— Аюны уятырга менә дигән әйбер бит бу! — дип, кишерне йоклап яткан аюның маңгаена җибәргән. Аю тәмле төшләр күреп ята икән, сикереп торган да үкереп оясыннан чыккан. Җир тетри, дип курыккан, бичара. Җирнең тетрәмәвен белгәч, авырткан маңгаен кашырга тотынган. Кишерне әйләндереп-әйләндереп караган да тәпие белән сытмакчы булган. Кишер телгә килгән:

— Аюкаем, матуркаем, зинһар, тимә миңа, мине җәзалыйсың килсә, җиргә генә күм, эһ тә итмәм, чыдармын,— дигән.

Аю ул әйткәнчә эшләгән. Яз җиткәч, кишер тишелеп чыккан да зур булып үскән. Шуннан соң аю белән төлке кишерне икесе ике якка тарта башлаганнар.

Аю:

— Кишер минеке, мин аны җиргә күмдем,— ди икән.

Төлке:

— Юк, минеке, чөнки синең маңгаеңа мин чәпәдем,— дигән.

Сугышып ук киткәннәр.

Ә куян, аю белән төлкенең сугышканын күреп, кишерне тартып алган да, җырлый-җырлый, балалары янына кайтып киткән.

Аю белән төлке һаман да кишерне бүлә алмыйча сугышалар, имеш.

Ә куянга шул гына кирәк. Ул тамагы тук булгач, рәхәтләнеп яши икән.



# *ЗУРКОЛАК БЕЛӘН ТЕЛЕФОН*

Бервакыт фил малае Зурколак балалар бакчасында телефон күргән. Балалар бер-берсе белән телефоннан сөйләшәләр икән:

— Алло! Алло! Дин-ди-лин! Дин-ди-лин! Мин — тюлень!

— Алло! Алло! Дин-ди-лин-дин-ди-лин, мин — тиен!

— Дин-ди-лин! Дин-ди-лин! Мин — куян!

Билгеле инде, Зурколакның да телефоннан сөйләшәсе килгән. Тик телефон трубкасы Зурколакның колагы өчен бик тә кечкенә булган. Колагына куюы булган, телефон трубкасы-ние белән колагы эченә кергән дә киткән.

Зурколак тегеләй иткән, болай иткән, әле уң, әле сул колагын селкеткән, тик телефон барыбер чыкмаган, колак буйлап сәяхәткә киткән.

— Чыгасың килмәсә, ят шунда,— дигән Зурколак һәм телефон турында оныткан. Тик тюлень, тиен, куян баласы бу турыда онытмаганнар. Алар Зурколакның муенына менеп атланганнар да аның колагыннан кычкыра башлаганнар:

— Чык инде! Дин-ди-лин, тизрәк чык! — дигәннәр алар.

Тик телефон чыгарга уйламаган да.

Җәнлек балалары тегеләй иткәннәр, болай иткәннәр, шуннан соң бер-берсе белән сугышып ук киткәннәр.

— Чыгарга уйламас та шул, телефон трубкасын син күбрәк дөбер-шатыр китерден,— дип, бер-берсенә сылтаганнар һәм әрепләшә-сугыша торгач, фил баласының колагына кереп киткәннәрен сизми дә калганнар.

Ә Зурколакка нәрсә? Ул боларның берсен дә сизмәгән.

— Әле генә монда иделәр бит. Кай арада барысы да юкка чыкты соң? — дип уйлаган һәм колагы кычытуга чыдый алмыйча сикеренә башлаган. Шулай булмый

2*

ни, бер колак эчендә телефон, ә телефон янында күпме җәнлек баласы дөбер-шатыр килсен әле! Ул колагын борыны белән дә кашып караган, койрыгын да селкеп маташкан, тик колак эчендәгеләр уйнап арып-талганнан соң, йокыга киткәч кенә колагы кычытудан туктаган. Алар йоклап киткәч, ул да тынычлап йокыга киткән.

Җәнлек балаларының әниләре өйләренә кайткач, балаларын тапмаганнар. Алар нык кайгыга төшкәннәр.

— Минем баламны чуртан йоткандыр! — дигән тюлень.

— Минем баламны карчыга алгандыр! — дигән тиен.

— Чуртанның кирәген бирәм! — дигән тюлень.

— Карчыганың күзен чокыйм! — дигән тиен.

— Төлкенең койрыгын өзәм! — дигән куян.

Киткәннәр болар. Тюлень — чуртанның, тиен — карчагының, куян — төлкенең кирәген бирергә.

Ә тегеләр үзләре кара кайгыда икән. Аларның да балалары Зурколак колагында булганнар бит.

— Әйдәгез, бергәләп эзлик! — диешкәннәр алар.

Аларның шулай җир селкетеп балаларын юллап йөрүеннән Зурколакның да колагы селкенгән. Колагы селкенгәч, андагы җәнлек балаларының колагы гына түгел, бөтен җире селкенгән. Алар куркышып уянганнар һәм җир селкенә башлады, дип, төрлесе төрле якка ышыренергә урын эзләп йөгерешә башлаганнар. Шулай йөгерә торгач, бер урында яктылык күргәннәр һәм шуннан атылып тышка чыкканнар. Үзләре белән телефонны да тартып чыгарганнар.

Җәнлекләр балаларын кочаклап алганнар. Ә телефонны иң биек агач башына элеп куйганнар. Озын юлдан арып кайткан кошлар анда кунып ял итәләр һәм берберсенә хәбәр бирәләр икән:

— Дин-ди-лин! Дин-ди-лин! Дин-ди-лин!



# НЕЧКӘБИЛ БЕЛӘН АЮ

Яшәгән, ди, Нечкәбил. Бал кортлары арасында иң нечкә биллесе генә түгел, иң төпчеге дә булган. Туганнары аны бик ятратканнар. Үсә төшкәч, үзләре белән бал җыярга өйрәтмәкче булганнар. Тик Нечкәбил:

— Мин сез җыйганны гына ашарга яратам,— дигән.

Туганнары:

— Эшләмәгән ашамый! — дигәннәр.

Нечкәбил барыбер бал җыймаган, җәй буена чәчәктән чәчәккә кунып, бал белән үзе генә тукланган. Кышка да ашарга кирәк булырын уйламаган. Тәмлене эзлиэзли бервакыт бик еракка очып киткән. Кире кайтырга уйлаганда инде кыш булган. Нечкәбил ары караган, бире караган, кайтыр юлны оныткан. Шулай калтыранып, ачка тилмереп йөри торгач, аю өненә егылып төшкән.

Аю, тәпән белән бал җыеп, кышкы йокыга талган булган. Бал корты җылынгач, аның тәпәненнән рәхәтләнеп бал ашаган. Бал шундый нәрсә ул: бер капсаң — биш, биш капсаң егерме биш тапкыр кими. Кыш чыкканчы тәпәндәге бал беткән. Берзаман аю бал ашыйм дип йокысыннан уянса — тәпәндә бармак белән яларлык та бал калмаган булган.

Аю шулхәтле ачуланган, бал кортын тотып сытыйм дияе булган, тегесе аның тырнаклары арасыннан качып котылган.

Шуннан соң инде аюның бал җыюдан гайрәте чиккән, кышка бал урынына корсагына май гына җыя башлаган. Йоклаган чагында ашыйсы килсә, күзен ачмыйча гына корсагын сыпыра да тәпиен авызына кабып суыра, ди.

Нечкәбилгә бу зур сабак булган. Ул туганнары янына кайткан да алар белән бергә кышка бал җыя башлаган.

# БАБАЙ ТҮБӘТӘЕ

Бер бабай болында печән чаба икән. Шунда аның борынына күбәләк килеп кунган. Күбәләкне куркытмас өчен бабай чалгысына таянып тын калган. Тик күбәләк тиз генә очып китәргә уйламаган. Аның очып киткәнен көтә торгач, бабайны йокы баскан. Шунда аның түбәтәенә бер кош оя ясаган, йомырка салган, бала чыгарган. Алар үскәннәр, ояны тарсынып кыбырсый башлаганнар һәм аска карап:

— Нинди биектә икән безнең оябыз, егылып төшсәк, чәлпәрәмә киләбез,— дип куркышып, бер-берсенә ныграк сыенышканнар.

Ул арада бабай уянган, төчкереп җибәргән, борынындагы күбәләк куркуыннан очып киткән. Бабай чалгысын селтәнә башлаган. Түбәтәендәге кошлар:

— Көчле давыл чыкты,— дип, тагын да ныграк куркышканнар.

Чалгысын селтәнә торгач, карт, маңгаеннан тирен сөртмәкче булып, кулъяулык эзләгән, тапмагач, түбәтәен салган. Салуы булган, кош балалары очып киткәннәр. Бабай, маңгай тирен түбәтәенә сөртә-сөртә, аларга хәерле юл теләп, кулын болгап калган.



# ЗУРКОЛАК БЕЛӘНҺАВА ШАРЫ

Зурколак урманда һава шары тапкан. Фил баласы моңа бик куанган, шарны алган да шунда ук кабартырга тотынган. Шар кабара торгач, Зурколак хәтле булган. Тик Зурколак кабартудан барыбер туктамаган. Кабара торгач, берзаман шар эченә үзе дә кереп киткән.

Бу вакытта шар яныннан куян баласы үтеп бара икән. Ул шарны күргән дә кулларын чәбәкләгән.

— Ой, бик әйбәт булды әле бу, кара нинди зур шар! — дигән дә үзе белән тәгәрәтеп алып киткән.

Ул арада җил чыккан. Җил дә шар артыннан йөгергән. Йөгерә торгач, шарны һавага күтәреп алып та киткән.

Очалар шулай шар, шар эчендә фил, ә куян исә шарга тотынган. Аның шарны җилгә бирәсе килмәгән, шуңа чатырдатып шарга ябышкан.

Җил әйтә икән:

— Шарны җибәр! Юкса миңа аны очыртып йөрүе авыр!

Куян әйтә икән:

— Бирермен менә! Шарны беренче булып мин таптым!

— Ах, шулаймыни әле! — дигән дә җил шарны куяны-филе белән бергә әллә кая ук алып киткән.

Фил баласы исә шар эченә кергәч, анда рәхәтләнеп йөри башлаган. Арыгач, ятып йоклаган.

Җил күпме тырышса да, барыбер шарны озак очыртып йөртә алмаган, аңа авыр шарны җиргә төшереп калдырырга туры килгән.

— Кире куян! — дигән ул.— Шарың да, үзең дә кире икән! Үзеңә бөтен җир шарын күрсәтеп, һавада очыртмакчы идем, ә ул барыбер җиргә тарта!

Шар эчендә фил баласы йоклап ятканын белмәгән шул ул.

Шар җиргә төшкәч шартлаган. Шарның тавышыннан куркып, Зурколак уянган да әнисе янына йөгергән.

— Әни! — дип кычкырган ул.— Әле генә шарым кулымда иде, кая китте икән? — дип бик гаҗәпләнгән.



# *МАКТАНЧЫК ЧЫПЧЫК*

Булган, ди, бер чыпчык, үзе шундый мактанчык. Бүтән чыпчыклар аның мактанчыклыгын белеп бетергәннәр, тыңлап та тормыйлар, яныннан дәррәү күтәреләләр дә очып китәләр, ди. Ә чыпчык моны үзеннән куркулары дип аңлаган. Бүтәннәрне дә куркытасы килгән моның. Карга оясына менгән дә:

—Чык-чык, мин чыпчык! — дигән.

Карга исә аңа:

— Кар-кар, йөрмә монда эч пошырып, минем эшем бар,— дигән.

Чыпчык аның саен:

— Монда чык, монда чык,— ди икән.

Карга, бу тиленең кирәген бирәсе бик килсә дә, бала чыгарып утырганга, чыпчыкның чәрелдәвен ишетмәс өчен башын канат астына тыккан.

Чыпчык карга миннән курыкты, дип уйлаган, борынын тагын да ныграк чөйгән, мәче башлы ябалакны да куркытмакчы булган. Янына килгән дә:

— Монда чык, чык-чырык! — дигән.

Тик ябалак төнге аудан бик арып кайткан. Ул да:

— Эч пошырып йөрмә әле! — дигән дә тегенең чәрелдәвен ишетмәс өчен колагына чүбек тыгып куйган.

Тиле чыпчык ябалакны да куркыттым, дип уйлаган. Тилгән янына киткән.

— Тили-тили, тилебәрән орлыгы ашаган тилгән, монда чык,— дигән.

Тилгән кояшта кызынып ята икән. Чыпчыкның черкелдәвенә каршы:

— Юк, юк, мин чыкмыйм, син бигрәк матур кош, үзең миңа кияүгә чык! — дигән.

Чыпчык тилгәннең бу тәкъдименнән башы әйләнеп чак кына артка аумаган. Чөнки әле моңарчы бер генә чыпчыкның да тилгән белән бергә яшәгәне булмаган.

— Чыгам, чыгам! Хәзер үк чыгам! — дип, куана-куана тилгәннең кочагына ук кереп киткән.

Тилгәнгә шул гына кирәк булган. Ул чыпчыкны капкан да йоткан.

# *КАВЫН*

Яз көне бакчада яшелчә утыртканда, әтисе Нәҗиянең кулына бер орлык салган.

— Менә бусын син утыртырсың,— дигән.

Нәҗия орлыкны зу-ур түтәлгә утырткан. Орлык зу-ур булып тишелеп чыккан. Күзгә күренеп үсә дә башлаган. Чәчәк аткан һәм кавынга әйләнгән. Зур түтәл генә аңа аз тоелган, коймага менгән, коймадан агачка, агачтан күктәге болытка ук менгән. Болыт, бичара, иптәшләреннән аерылып, бер урында эленеп торырга мәҗбүр булган.

Нәҗия әтисе янына йөгергән:

— Кавыныбыз безне ташлап китә! — дигән.

Бергәләшеп кавынның сабагыннан тарткалый башлаганнар.

Тарткалыйлар, тарткалыйлар, һич кенә үсүеннән туктата алмыйлар. Үсә дә үсә, үсә дә үсә генә. Болытны да каплап алган, зәңгәр күкне дә каплаган, тирә-якны көпә-көндез дөм караңгылык баскан.

Шул чагында бер кәҗә килгән дә, тегеләр сабакны тартып азапланганда, аскы өлешен кимереп тә бетергән. Сабагы тамырдан аерылгач, болытлар өстендәге кавын аска егылып төшкән һәм вак кисәкләргә таралган. Ашыйсы килгән бөтен кешегә җиткән, кәҗәгә дә өлеш чыккан.



# ШИФАЛЫ СӨТ

Куян баласы кичкә таба авырып киткән. Әнисе докторга йөгергән. Ә доктор керпе икән.

— Керпекәем, апакаем, балама әллә нәрсә булды, нишләргә дә белмим,— дигән.

Керпе, куян баласын карагач, болай дигән:

— Терелсен дисәң, кайнаган сөт эчер.

Куян шөбһәгә төшкән. Кайнаганы түгел, кайнамаганы да юк бит әле аның, дип уйлаган.

Киткән бу елый-елый урман буйлап. Каршысына саескан очраган.

— Нигә елыйсың, берәр кайгың бармы әллә? — дип сораган.

— Ничек инде еламыйсың? Сабыем үләргә ята. Керпе доктор кайнаган сөт эчерергә кушты, каян табарга да белмим,— дигән.

— Бар, өеңә кайт, сабыең янында утыр, мин сиңа сөтне үзем табармын,— дигән.

Куян кайтып киткән. Саескан сыер янына килгән.

— Сыеркаем, матуркаем, бераз гына сөт бир әле,— дигән.

Сыер әйткән:

— Бик бирер идем дә, хуҗа хатын әле генә сөтемне базарга чыгарып сатты, иртән кил,— дигән.

— Иртәгә хәтле куян баласының үлүе бар шул,— дигән саескан.

— Ярар алайса,— дигән сыер.— Хәзер сөт җыеп карыйм.

Шуннан болынга чыккан, күп итеп үлән ашаган, җилененә сөт төшкән һәм саескан җитәрлек кадәрле сөт савып алган. Шуннан соң куян янына кайтып киткән. Куян сөтне кайнаткан һәм баласына эчергән, баласы терелгән.



# *ШУК КАРЛЫГАЧ*

Урман уртасындагы бер болында кыргый көнбагышлар үскән. Төн уртасы җиткәч, көнбагышлардан берәм-берәм матур кызлар сикереп төшкәннәр дә күңел ачарга тотынганнар. Учак ягып, аның тирәсендә биегәннәр, җырлаганнар, ут аша сикереп үзләрен җитезлектә сынаганнар, әкиятләр сөйләгәннәр, табышмаклар әйтешкәннәр. Офыкта таңның беренче нурлары күренү белән кире ояларына сикереп менгәннәр дә көнбагышларга әйләнгәннәр.

Урманның икенче башында төнбоеклы күл булган. Ай калыккач, төнбоеклар көймәгә әверелгән, ул көймәләрдә иңнәренә ук-җәя аскан баһадир егетләр утырган. Егетләр төне буена көймәләрдә йөзгәннәр, ук атышканнар, алар да бер-берсен уңганлыкта-тапкырлыкта сынаганнар. Таң алдыннан арып-талчыгып көймәләренә башларын салып йокыга талганнар, күл өстен кабат төнбоеклар каплаган.

Көнбагышлар басуында карлыгач яшәгән. Ул бик шук булган. Көнбагышларны авызына каба да өйләнергә вакытлары җиткән егетләрнең кесәләренә илтеп сала икән. Егет кесәсенә кулын тыккач, кәләш тартып чыгарган. Егет шунда ук гашыйк була һәм өйләнешергә тәкъдим итә. Кыз, карлыгачның үзен ни җитте егет кесәсенә салмаслыгын белгәнгә, шунда ук риза була.

Шулай бервакыт карлыгач күбрәк мутланып ташлый, караңгы төшкәнче оясына кайтып җитә алмый. Шуннан соң ул күл өстендә йөзеп йөргән төнбоек яфрагына ял итәргә куна. Ай болытлар арасыннан чыгуы була, күк йөзе балкып китә, күл өстендәге төнбоек чәчәкләре, дәррәү ачылып китеп, көймәләргә әверелә, ә ул көймәләрдә берсеннән-берсе чибәр егетләр пәйда була. Таң аткач, күл өстен тагын төнбоеклар каплый.

Карлыгач болынга очып кайткан һәм көнбагышлар-

ны төнбоеклы күлгә ташыган. Бер генә чәчәк тә көнбагышсыз калмаган.

Төн җиткәч, ай тагын болытлар арасыннан башын чыгарган. Күл өстендә көймәләр чайкала башлаган. Егетләр уянып җәяләренә тотынмакчы булганнар, тик кочакларында йоклап яткан кызларны күргәннәр һәм барысы да берьюлы гашыйк булганнар.

Кызлар да йокыларыннан уянганнар. Билгеле инде, алар да егетләргә шунда ук гашыйк булганнар.

Таң алдыннан егетләр — төнбоекка, кызлар көнбагышка әйләнергә оныталар. Көймәләрнең төнбоекка әйләнеп ябылуы була, барысы да күл уртасына егылып төшәләр. Шуннан алар яр буена йөзеп чыгалар.

Алар бер-берсенә шулхәтле гашыйк булалар, аларның мәхәббәте каршында күлнең дә тылсымы югала, чәчәкле матур болынга әйләнә.

Яшьләр шул болында яшәп калалар, йортлар салалар, иген үстерәләр һәм берсеннән-берсе матур балалары туа.

Ә карлыгач барыбер шуклыгын ташламый. Җиткән кызлар яшереп кенә сөйгәннәренә кулъяулык чиккән арада, карлыгач арадан берсенең кулъяулыгын ала да егетләрнең берсенең кесәсенә сала һәм алар арасында дөрләп мәхәббәт уты уянуыннан үзенә тәм таба.



# *ТЫЛСЫМЛЫ БАШМАКЛАР*

Чикерткә базардан башмак сатып алган. Башмаклар шундый матур, шундый җиңел икән. Аякларына киюе булган, чикерткәне очыртып алып киткәннәр. Һич кенә дә туктап булмый икән.

Шундый тылсымга ия булган шул башмаклар.

Башмаклар чикерткәне болытлар өстенә алып менгән. Чикерткә биеклектән куркып, күзләрен чытырдатып йомган һәм бер болытка тотынган.

Шулай йөри торгач, ком чүле өстенә җиткәннәр болар. Анда кактуслар чәчәк атып утыра икән. Ә кактус чәчәкләренең искиткеч матур булуын сез беләсезме? Алар үзләре генә чәнечкеле, ә чәчәкләре бер дә чәнечкеле түгел, күз явын алырлык.

Башмакларның шул чәчәкләрне якыннанрак күрәсе килгән. Тотканнар да болыттан төшеп калганнар болар. Иң матур бер кактусның ботагына килеп кунганнар. Чикерткә дә алардан калмаган. Калырга, башмаклар аның аягында булган бит.

Кактусның чәнечкеле булуын белмәгәннәр шул алар. Төшү белән чәнечкеләргә кадалганнар. Чикерткә алай иткән, болай иткән, башмакларын көчкә ычкындырып, җиргә төшкән. Башмаклар да кактустан төшкәннәр дә чикерткәдән башка гына атлап киткәннәр. Чикерткә башмакларны куа киткән. Тик куып кына җитә алмаган. Аңамы соң тылсымлы башмакларны куып тотарга?

Шул көннән бирле чикерткә әле дә сикерә-сикерә башмакларын куып йөри икән.



# ТӘГӘРМӘЧ

Урман юлыннан арбасына печән төяп, бер абзый бара икән. Тырпаеп торган агач төбенә эләгеп, арба тәгәрмәченең берсе ычкынып киткән. Ә абзый берни сизмәгән, печән өстендә йокымсырап баруын дәвам иткән.

Тәгәрмәч тәгәри-тәгәри арбаны да, арбаны тартып баручы атны да узып киткән һәм бер агачка бәрелгәнгә хәтле тәгәрәгән дә тәгәрәгән. Үзе җырлый икән:

— Тәгәримен, тәгәримен, минем эшем тәгәрәү,
Тәгәрәүнең яме бар, ә печәннең тәме бар...

Тик агач төбенә бәрелүе булган, җыры ярты юлда өзелеп калган. Агач төбендә куян балалары уйнап ята икән. Алар куркышып төрлесе төрле якка качып, үлән арасына посканнар.

— Әллә җир тетрәп безнең болынны селкетәме?

— Әллә яшен безнең агачны суктымы?

— Ул шундый зур иде, күзләре тәлинкә чаклы иде.

— Юк, ул арыслан иде...

— Юк, ул дию пәрие иде,— диешкәннәр.

Күпме бәхәсләшсәләр дә, бер фикергә килә алмаганнар. Шуннан соң куяннар әкрен-әкрен генә ояларына якынайганнар, агачка бәрелеп сынган тәгәрмәчне күргәч, бер-берсеннән рәхәтләнеп көлешә башлаганнар, иреннәре ярылмыйча, күзләре кылыйланмыйча көлүдән туктамаганнар, ди.



## *КАБАК ҺӘМ АНЫҢ ДУСЛАРЫ*

Шәһәрдән ерак түгел җиләк-җимеш бакчалары бар. Агачлар яз җиткәч, яфракка бөреләнгәндә дә, көннәр җылынгач, чәчәк атканда да, җәйләрен җимеш белән капланганда да, көзләрен өлгергән җимешне җыеп алганда да куаналар икән.

— Матур булуы бик күңелле шул,— диешкәннәр алар. Ә җимешләр өлгергәч, вакытында җыеп алсалар, тагын да күңеллерәк.

Менә быел да җимеш җыярга вакыт җиткән. Бакча хуҗалары җимешнең күплегенә сөенә-сөенә уңыш җыйганнар. Аларның куануларын күрү агачларга да бик күңелле булган.

Тик койма буенда үсеп утырган кабакны өзәргә онытканнар. Кабак моңа кайгырган. Хуҗалары тагын килмәсме, дип көткән. Ә хуҗалары кабак турында бөтенләй онытканнар. Кабак үзен онытканлыкларын белмәгән. Койма буендагы биек баганага менгән дә берәрсе күренмәсме, дип юлдан күзен алмаган. Шулай үсә торгач, багана башына ук менеп киткән. Аска карaса, башы әйләнүдән дер-дер калтырана башлаган. Ә багана башында үрмәкүч җәй үргән челтәрләрен базарга чыгарып сатар өчен үтүкләп утыра икән. Кабак, егылып төшмәс өчен, челтәрләргә тотынмакчы булган икән, үрмәкүч аны ачуланырга тотынган:

— Әй, син, тик кенә тор! Челтәрләремне ертасың! Минем челтәрләрем бик нәфис, алардан күбәләкләр үзләренә канат тегә. Тукта әле, нишләп син шулхәтле биек мендең? — дигән.

— Мендем шул,— дигән кабак.— Мин хуҗамны көтәм.

— Кайчан килә соң?

— Килмәве булгандыр инде...

— Хәлең чынлап та шәптән түгел икән,— дигән үрмәкүч.— Әйдә, мин ярдәмгә бүтән үрмәкүчләрне чакырам.

Кабак аларның ярдәменнән башка үзе генә төшмәкче булган, башы әйләнүдән чак кына егылмыйча калган.

3*

— Үзе төшә, имеш! — дигән үрмәкүч.— Багана башына менүе генә җиңел ул, ә менә төшүе... Әй, әй, селкенмә, дим! Әй, әй! Үрмәкүч туганнар! Килегез, ярдәм итегез!

Ярдәмгә бакчадагы үрмәкүчләрнең барысы да җыелган. Алар артыннан чыпчыклар, песнәкләр килгән. Барысы да кабакны бик кызганганнар.

— Бичара кабак! Ничек кыш чыгар инде ул багана башында? — диешкәннәр.

— Кабак туган егылып төшмәсен өчен челтәрдән ятьмә үрергә кирәк. Минем сатарга дигән челтәрләремне дә ятьмәгә кушарбыз, көннәр җылыткач, яз көне иртәрәк эшкә тотынырмын да күбәләкләр уянганчы тагын үрермен әле. Ә сез, чыпчыклар, песнәкләр кабакны тотып торыгыз.

Чыпчыклар, песнәкләр үзара сөйләшергә тотынганнар:

— Көчебез җитәр микән? Ул шундый дәү, без бәләкәй...

— Аның каравы без күп, ул берүзе...

— Тырышып карыйк башта...

— Җил исә башлады... Хәзер бәреп төшерә...

— Яңгыр да явам дип тора...— диешкәннәр алар.

— Мин исми торам,— дигән җил.

— Мин яумый торам,— дигән яңгыр.

— Мин тынымны да чыгармыйм,— дигән багана.

Үрмәкүчләр баганаwell челтәр ятьмә белән әйләндереп алганнар. Кайсы элек үргән челтәрен алып килгән, кайсы яңадан үргән, багана тирәсеннән агач башларына, коймага исәпсез-хисапсыз челтәрләр сузганнар да кабакны сабагыннан тарткалый башлаганнар. Ә чыпчыклар, песнәкләр өстән этеп торганнар. Тик кабакны төшерә алмаганнар. Шуннан соң аларга ярдәмгә кемнәрне чакырганнар дип уйлыйсыз? Тычканнарны!

Кабак сүзен ишеткәч, тычканнар йөгерешеп килгәннәр. Кабак орлыгын алар да бик ярата икән. Тик бу юлы кабак орлыгы белән сыйланырга түгел, аңа ярдәм итәргә кирәк шул. Бер армия тычкан өскә үрмәләп менгән, бер армиясе аста калган. Өскә менгән тычканнар кабакны әйләндереп алган ятьмә-челтәрләр ычкынып кит-



мәсен өчен бер тәпиләре белән баганага, бер тәпиләре һәм борыннары белән кабакка, бер тәпиләре һәм койрыклары белән челтәргә ябешкәннәр, ә бер тәпиләрен запаста тотканнар. Астагылары кабакны сабагыннан әкрен-әкрен аска тарта башлаганнар. Көн тартканнар, төн тартканнар, шулай итеп, кабакны исән-имин тартып төшергәннәр болар. Кабакның бер генә җире дә сыдырылмаган хәтта.

Тычканнар аның тирәсендә:

— Нинди зур кабак!

— Нинди матур кабак!

— Нинди батыр кабак!

— Нинди түзем кабак! — дип куанып әйлән-бәйлән уены уйнаганнар.

— Бик зур рәхмәт, сезгә дусларым! — дигән кабак.— Мин сезне тәмле төшләрем белән сыйлар идем дә, хуҗам янына кайтасым бар.

Аңа берсе дә үпкәләмәгән. Тәмле кабак төшләре белән бүтән чакта сыйланырга булганнар. Үрмәкүчләр тычканнарга үзләре үргән челтәрләрне биргәннәр. Тычканнар бик куанышканнар:

— Бигрәк матур челтәрләр...

— Туй күлмәкләренә бик шәп бу...

— Тәрәзәләргә пәрдә итеп эләрбез...

— Бишеккә чыбылдыклар ясарбыз! — диешкәннәр.

Кабак аска төшүен төшкән дә, төшкәч, ни эшләргә дә белмәгән.

— Хуҗам бакчага килмәсә, катып үләрмен инде,— дип кайгырган.

Үрмәкүчләр:

— Без сиңа бүтән булыша алмыйбыз, үпкәләмә,— дигәннәр.

Кошлар да:

— Пип-пип-пип... Безнең дә кулыбыздан килми, пип-пип-пип,— диешкәннәр.

Һәм һәркайсы үз юлы белән киткәннәр. Тычканнар, зу-ур мәче күреп, ояларына посканнар.

Ә бу вакытта берәр тәмле ризык булмасмы, дип, урманнан бакчага куян килгән. Килгән дә кабакны күргән. Тәпиләре белән шакый башлаган:

— Тук-тук-тук, син кем буласың? — дигән.

— Мин кабак булам. Мин сине беләм. Син — куян,— дигән кабак.

— Каян беләсең? — дигән куян.

Кабак әйткән:

— Яз көне әниеңнән адашып калганда, минем яфракларым астында төн кунган идең. Без икебез дә бик бәләкәй идек, бер-беребезгә сыенып җылындык. Ул төнне кырау төшкән иде. Син булмасаң, мин ул чагында ук туңып үлә идем,— дигән.— Хәзер миңа берәү дә ярдәм итә алмас инде. Хәлләрем хөрти...

Куян да кабакны исенә төшергән. Кабак булмаса, үзе дә катып үләсе икән.

— Син борчылма! Хәзер куян дусларымны чакырам. Алар булышырлар. Куян дусларым, сез кайда? — дигән.

Аны ишетеп, бүтән куяннар да ярдәмгә ашыкканнар. Кабакны күргәч:

— Бу кабак бик тә тәмледер, шулхәтле зур үсмәс иде,— диешкәннәр.

Бер үсми калган куян:

— Ничек шушы хәтле зур булып үстең син, ә? Серен миңа да әйт әле. Бу хәтле үссәм, бүредән дә, төлкедән дә курыкмас идем,— дип, кабак тирәсендә йөгерә икән.

Куяннар аңа карап көлешкәннәр генә.

— Тиле буйга үсә,— диешкәннәр алар.

Куяннар кабакны тәгәрәтә башлаганнар. Тәгәрәтә торгач, бүре оясына килеп җиткәннәр. Бүре балалары сугышлы уйный икән. Куяннарның кабак тәгәрәтеп килгәнен күргәч, гаҗәпләнүләренең чиге булмаган:

— Карагыз әле, карагыз, нинди куркыныч җанвар килә,— диешкәннәр.

Бүре балалары куркып төрлесе төрле якка качкан.

Куяннар да бүре балаларының йөгерешкәнен күреп, кабакны калдырып качканнар. Шунда бәләкәй куяннан:

— Йә, кабак кебек үсәсең киләме инде? — дип сораганнар.

Бәләкәй куян җавап урынына дер-дер калтыранган гына. Ул үзенең бәләкәй булуына бик нык сөенгән, башкалардан иң тиз чабучы ул булган бит.

Менә ана бүре аудан кайткан. Ул кабакны күреп гаҗәпләнгән, иснәп тә, тотып та караган.

— Ит исе дә килми, күтәреп тә булмый, бу нәрсә икән? — дип аптыраган. Әниләрен күргәч, бүре балалары да:

— Юкка куркышканбыз икән! Әйдәгез, без аны шар итеп тәгәрәтеп уйныйбыз! — диешкәннәр.

Бүре балалары кабакны тәгәрәтә башлаганнар. Тәгәрәтә торгач, оядан читкә киткәннәрен дә, юлга чыкканнарын да, юлдан шәһәргә килеп кергәннәрен дә сизми калганнар. Кешеләр әкәмәт тамаша күреп йөгерешә башлаганнар.

— Футболчы бүреләр килгән, тамаша күрми калмагыз,— диешкәннәр.

Тамаша карарга саескан да килгән. Ул бүре балаларының уйнаганын карап торган-торган да:

— Дөрес уйнамыйсыз, хәрәмләшми генә уйнагыз! — дип кычкырган.

Бүре балалары бер-берсе белән тарткалаша башлаганнар:

— Мин хәрәмләшмим, син хәрәмләшәсең!

— Юк, син үзең хәрәмләштең!

Шул чагында кабак хоккей уйнаучы бүреләрне карарга җыелган кешеләр арасында үзенең хуҗасын күреп алган да туп-туры аңа таба тәгәрәгән. Хуҗасы да аны таныган, күтәреп өенә алып кайткан. Өйгә кайткач, тәмле итеп кабак бәлеше пешергән, теләгән һәркемне сыйлаган, ә төшен яз көне тычканнарны сыйлар өчен киптереп куйган. Бүре балаларын да сыйламакчы булган, тик алар әллә кайчан урманга элдергән булганнар.

## *БОТКА НИГӘ ТӘМЛЕ?*

Булган, ди, бер кыз. Ул әнисе пешергән ризыкларны ашарга бер дә яратмаган. Кәнфит-перәннек кебек татлыдан-татлыны гына сораган. Әнисе тегеләй әйтеп караган, болай әйтеп караган, кызый:

— Моны ашагач эчем авырта! — дип ялганлый икән.

Әнисе аны врачка алып барган.

Врач әйткән:

— Сезнең кызыгыз тап-таза,— дигән.

Кыз тагын хәйләгә сабышкан.

— Күзем авырта! — дигән.

Әнисе тагын врачка алып барган.

Врач:

— Кызыгызның күзләре сау-сәламәт,— дигән.

Әнисе алдына тагын ашарга куйган. Кыз тәлинкәне эткән дә:

— Колагым авырта! — дип акырып еларга тотынган.

Әнисе аны тагын врачка алып барган.

Врач:

— Кызыгыз бик әйбәт ишетә,— дигән.

Шулай булса да әнисе кызына татлыдан-татлы ризык кына ашатырга мәҗбүр булган. Шулай итә торгач, әнисенең ипи алырга да акчасы калмаган. Шуннан әнисе манный боткасы пешереп биргән. Кыз:

— Манный боткасын песнәкләр ашасын! — дип акырып-бакырып еларга тотынган.

Әнисенең ачуы килгән.

— Мин пешергән ризыкларны яратмагач, корт чүпли торган песнәккә әверел! — дигән.

Кыз песнәккә әверелгән, очып киткән, песнәкләр көтүенә кушылган.

Тик ул чын песнәк булмаган шул. Песнәкләр яратып ашаган бөҗәкне авызына да каба алмаган.

Шулай йөри торгач, ачыккан һәм үзләренең өенә кай-

тып җиткән. Ачык тәрәзәдән очып кергән, өстәлдә үзе ашамый калдырган ботканы күргән. Тәлинкәгә очып кунган да ботканы ашарга тотынган. Үзе ашый икән, ә үзе:

— Тәмле, тәмле, нишләп мин моңарчы шулхәтле тәмле икәнен белмәдем икән,— дип сайраган.

Ашый торгач, корсагы шартлап ярылырдай булып тулган. Һәм шуннан кемгә әйләнгән дип уйлыйсыз? Билгеле инде, үзенә!

Шуннан соң әнисе нәрсә пешереп бирсә, шуны ашаган, аны бүтән бимазаламаган.



# *ТАГАН БАЛАЛАГАН*

Урманда куян баласы яшәгән. Әнисе аңа бик күп уенчыклар алган. Куян баласы аларны бишектә тирбәткән, аларга җырлар җырлаган. Ул аеруча өч уенчык куян белән яратып уйнаган.

Мин куяннар әннәсе,
Әннәсе дә нәннәсе.
Өчәү минем бәбием,
Өчесе дә нәнием.
Зуры сикерә — мурт-мурт,
Уртанчысы — һүп-һүп!
Иң кечесе бик шаян,
Ике күзе дүрт-дүрт!* —

дип җырлаган ул.

Әнисе куян баласын тәмледән-тәмле ризыклар белән сыйлаган — балакаем тизрәк үссен, дип теләгән. Куян баласы әнисен юк-бар сорап тинтерәтмәгән, әнисе юкта да нишләргә белмичә аптырап тормаган, уенчыкларын уйнаткан, җырлаткан, биеткән, йокларга яткырган, йокыларыннан торгач, тагын уйнаткан, биеткән. Әнисе исә урманнан тәмледән-тәмле ризыклар җыеп алып кайткач, аңа мактанган.

— Тамчы да курыкмадым, әнием! — дигән.

— Болай булгач, син көнләп түгел, сәгатьләп үсәсең икән,— дигән әнисе дә куанып.

— Әйе, көнләп түгел, сәгатьләп үсәм,— дип куанган куян баласы.

Бервакыт куян таган алып кайткан.

— Рәхәтләнеп атын, тагын да тизрәк үсәрсең! — дигән.

Куян баласы әнисен кочаклап алган һәм:

— Рәхмәт, әнием! Рәхмәт! — дип, куанычыннан кулларын чәбәкләгән.

---

* Шигырьләр Нәкый Исәнбәтнеке.

Таганны биек бер агачның аскы ботагына элеп куйганнар. Куян баласы уенчыкларын таганга утыртып, берәм-берәм атындырмакчы булган икән, тик берсе дә таганда тотынып тора алмаган, егылганнар да төшкәннәр. Чөнки аларның бер тапкыр да атынып караганнары булмаган шул. Куян баласы тегеләй иткән, болай иткән, шуннан соң утырып еларга тотынган. Җитмәсә, агач башында утырган саескан аны үртәргә тотынган:

Куян дигән киек
Арт аягы биек.
Алгы аягы тәбәнәк.
Таган атынам дигән иде,
Төште-китте тәгәрәп.

— Әйем! Син әшәке! Әни! — дип, әнисен чакырган куян баласы.

Тик әнисе аны ишетмәгән, ул җиләк җыярга киткән булган.

— И, мин сине зур үскән дип тора идем. Син бөтенләй бәләкәй икәнсең бит! — дигән саескан.

— Үсәм мин! Үсәм! — дигән куян баласы.

Ә саескан аның янына төшкән дә канаты белән куян баласының күз яшен сөрткән.

— Ярар, үпкәләмә,— дигән.— Мин шаярттым гына. Без синең белән күршеләр. Без бу агач башында ябалак белән бергә яшибез.

Куян баласы агач башына караса, чынлап та анда ябалак утыра икән. Аның таганга исе китмәгән, чөнки ул аны күрмәгән.

— Нишләп аның күзе йомык? — дип гаҗәпләнгән куян баласы.

— Йоклый ул,— дигән саескан.

— Хәзер уятам мин аны! Ябалак! Ябалак, дим! Әйдә, таган атын! — дип эндәшкән аңа куян баласы, тик ябалак селкенмәгән дә.



Саескан аңа ябалакларның төнлә ауда йөрүен, ә көндезләрен йоклавын, йоклаган чагында күпме генә кычкырсаң да, ишетмәвен әйткән.

— Алайса, әйдә, икәү атынабыз! — дигән куян баласы аңа.

Саескан белән куян баласы бергә таганда атына башлаганнар.

— Әй-әй-әй! Кемнең таган атынасы килә? Килегез, безнең белән атыныгыз! — дигәннәр алар.

Таганда атынырга песнәкләр дә, чыпчыклар да, тукран да, баласын ияртеп керпе дә, хәтта тычкан да килгән. Таганда атыну барысына да ошаган. Шулай итеп, кич җиткән. Барысы да кайсы кая йокларга таралган. Куян баласы гына йокларга теләмәгән. Ул таганда атынуын дәвам иткән. Атына торгач, утырган килеш йоклап та киткән. Әнисе аны күтәреп урынына салган.

Кояш батып, җир йөзенә караңгы төшкәч, ябалак йокысыннан уянган һәм ауга чыккан. Чыгар алдыннан баласына агачыннан төшмәскә кушкан.

— Минем дә синең белән ауга чыгасым килә! — дигән ябалак баласы.

— Канатларың ауга чыгарлык булмаган шул әле,— дигән ябалак.— Менә ныгыгач, чыгарсың!

— Канатларым үскәнче күпме вакыт бар әле! — дип уйлаган ябалак баласы.

Ябалак ауга киткән, ябалак баласы якын-тирәдән очып кайтмакчы булган. Тик әнисенең сүзе исенә төшкән. Шуннан соң ул агачыннан төшмичә генә аска караган һәм таганны күргән.

— Таган! Каян килгән бу? Кичә дә, аннан алдагы көннәрдә дә юк иде бит! Кемнеке икән ул? — дип аптыраган ул.— Әй-әй! Кем таганы бу? Миңа да атынырга ярыймы?

Тик аңа берәү дә эндәшмәгән. Эндәшергә, бөтен җәнлекләр һәм кошлар тәмле йокыда булган шул.

— Алайса, моны миңа урман бабай калдырып киткәндер,— дип уйлаган ябалак баласы һәм таганда atына башлаган. Таганда атыну ябалак баласына бик ошаган. Атына торгач, төн үткәнен дә сизмичә калган. Менә офык балкыган, яктырган, аннан кояшның беренче нурлары күренгән һәм кояш күтәрелә башлаган. Ул таганда утырган килеш йоклап киткән.

Ябалак та аудан кайткан. Ул бик арыган булган,ботакка куну белән күзләре йомылган. Ул, билгеле, таганны да, анда утырган баласын да күрмәгән. Ә иртә белән куян баласы таганда атынырга дип чыкса, анда ябалак баласын күргән.

— Әни! Таган балалаган! Таган балалаган! — дип куанган ул.

— Кит, таган нишләп балаласын? — дип гаҗәпләнгән әнисе.— Менә әкәмәт! Чыннан да балалаган икән шул!

Хәзер инде куян баласы борчыла башлаган.

— Болай булгач, таган мине атындырмас та инде,— дип уйлаган.

— Нигә атындырмасын? — дигән куян.— Баласына катыда йоклавы кыендыр, әйдә, синең йомшак караватка салыйк. Шулай итсәк, таган сиңа теләгән хәтле атынырга рөхсәт итәр.

Куян баласы, билгеле, риза булган. Ябалак баласын караватка кертеп салганнар. Куян баласы көн буе таганда атынган. Ә ябалак баласы исә көне буена йоклаган. Куян баласы бу юлы да таганда атынган килеш йоклап киткән. Әнкәсе аны тагын күтәреп алып кергән һәм ябалак баласы янына салган, үзе дә йокыга киткән.

Ябалак баласы караңгы төшкәч, йокысыннан уянып, тагын таган атынырга чыккан. Шул вакыт ябалак та ауга киткән. Ул да баласының өйдә юклыгын сизмәгән.

Ябалак баласы тагын таганда атынган көйгә йоклап киткән. Ябалак исә аудан кайтып килешли таганны да, анда йоклап утырган баласын да күргән. Тик аның яны-

на утыруы булган, күзләре йомылган. Ә иртән ...куян баласы таган атынырга чыкса, анда ике ябалак йоклап утырганын күреп, тагын да ныграк гаҗәпкә калган.

— Таган тагын балалаган! Таган тагын балалаган! — дип, әнисенә йөгергән ул.

«Көн саен таган балалап тормый инде, юкны сөйлисең», дисә дә, әнисе аларны күргәч, баласыннан да ныграк аптыраган.

— Берни эшләп булмый инде, балакаем,— дигән ул.— Әйдә, туйганчы йокласыннар. Йокылары туеп уянгач, сөйләшербез үзләре белән.

Тик бу көнне дә алар ябалак белән сөйләшә алмаганнар. Бүтән көннәрдә дә. Чөнки ябалаклар көне буе йоклаганнар, йоклап торгач, бергәләп ауга йөри башлаганнар. Шулай булмыйча, төне буена таганда канат кагына-кагына атына торгач, ябалак баласының канатлары ныгыган, үзе дә әнисе кебек зу-ур үскән. Әнисе аны ауга чыгарга, тычканнар тотарга өйрәткән. Ябалак баласы яңадан таганда атынам димәгән инде, анда нәниләр генә атынганын белгән ул.



# БОЛЫТНЫҢ КОЙРЫГЫ КАЙДА?

Яз җиткәч, көннәр җылынган һәм бер күлләвектә кыш чыккан бака малае бакылдык та уянган. Ул әле бик кечкенә булган, шуңа күрә үзе яши торган күлләвек аның өчен бик тирән, бик киң тоелган. Ул анда көне буена йөзгән, уйнаган. Уйнап арыгач, төпкә төшеп, ләм өстенә ятып ял иткән, су өстендә очкан чебен-черкиләрне күзәткән. Ашыйсы килсә, судан башын чыгарып авызын ачкан һәм вак чебен-черки аны-моны белештермичә туп-туры авызына ук килеп кергән.

Шулай көн артыннан көн үткән, төн артыннан төн үткән. Бакылдык үскән, менә дигән бака егете булган һәм яр буена чыккан. Караса, су бөтенләй кибеп бетә язган, ди.

Бакылдык үзе генә калгач, башта бик курыккан. Курыкмыйча, әниең кебек яратып үстергән күл юкка чыга язсын әле!

— Мин синең үскәнеңне генә көттем. Ә хәзер парга әйләнеп, болытка кушылам. Хуш, мин яраткан бака-бакылдык! — дигән күлләвек һәм болытка ияреп юкка чыккан.

Бакылдык болытны куып караган, сикереп тә тотмакчы булган, тик кая ул! Җитмәсә, каршына күзләрен усал елтыратып песи килеп чыккан.

— Тсс...— дигән ул.— Ары барырга ярамый. Тычканнарны куркытасың.

— Кемнәр соң алар тычканнар? — дигән бакылдык.— Үзләре мине куркытмасалар, мин дә аларны куркытмам.

— Алармы? — дигән песи.— Алар шундый матурлар, йомшаклар, наяннар. Телисеңме, мин сине тычкан белән сыйлыйм?

— Минем тычкан ашаганым юк шул,— дигән бакылдык.— Мин чебен-черки яратам.

— Фу! — дигән песи.— Чебен-черки дә булдымы ризык? Ярар, булышмасаң булышмассың. Тик бүтән күземә күренмә! Юкса, тычкан белән саташтырып, кабып йотуым бар!

— Юк, юк, күзеңә күренмәм! — дигән бака-бакылдык һәм ары сикергән. Һәм, песи юкмы дип, оясыннан башын чыгарып карап торган кыр тычканы янына ук килеп төшкән. Тычкан ялт итеп оясына качмакчы булган, тик бакылдык аның койрыгын эләктереп алган. Тычкан алай иткән, болай иткән, шуннан соң ялына башлаган:

— Зинһар өчен, җибәр, бакылдык абзыкаем, җибәр, җибәрсәң, мин сиңа оямны ук күрсәтермен! — дигән.

Бакылдыкның тычканны куркытырга ниятендә дә булмаган. Ул үзе ныграк курыккан. Шуннан соң ул аның койрыгын җибәргән һәм тычкан аны оясына алып төшкән. Аның оясы бакылдыкка бик ошаган.

— Суда гына түгел, коры җирдә дә яшәргә була икән бит,— дип уйлаган.

— Әйдә, икәү яшибез,— дигән тычкан.— Минем янга песи килсә, койрыгыннан тартып куркытырсың.

Бака риза булган. Шулай итеп, алар бергә яши башлаганнар.

Тычкан белән баканың бергә яшәвен бүтән тычканнар да ишеткән һәм алар үз күзләре белән күрергә теләп аның янына килгәннәр.

— Бу минем дустым — бака-бакылдык! — дигән аларга тычкан.— Ул безнең барыбызның да дусты булачак!

— Нинди батыр бака! — дип сокланганнар тычканнар.— Дус яшәргә без бик яратабыз, песи генә дус яшәргә ирек бирми, гел куркып яшәргә туры килә.

Шулай яшиләр болар. Бака-бакылдыкка тычканнар арасында әйбәт булса да, ул үзенең парга әйләнгән күлләвеген сагынган. Кичләрен оядан чыга да, болытларга карап моңая икән.





— Син нишләп бик боек,— дигән тычкан.— Безнең янда күңелсезме әллә?

— Минем суда чупырдыйсым, чебен-черки тотасым, күл төбеннән өскә — зәңгәр күккә карыйсым килә,— дигән бака.

— Кайда соң синең ул күлең? — дигән тычкан.

— Әгәр дә белсәм иде! — дигән бака.— Мин үскәч, ул парга әйләнеп, болытка иярде дә китте.

— Мин суны бөтенләй дә яратмыйм, миңа җир астында бик рәхәт,— дигән кыр тычканы.— Мин моннан ерак түгел елга барын беләм. Бәлки, ул сиңа әйтер.

Бака елга янына киткән.

— Минем күлемне алып киткән болытны күрмәдеңме? — дигән.

— Күрдем,— дигән елга.— Синең күлне урлаган болыт яңгыр булып миңа төште.

— Кая соң ул болыт? — дигән бакылдык.

— Хәзер ул су булып диңгезгә агып китте.

— Мине дә диңгезгә алып төш әле! — дигән бака.

— Һи, тиле бака! Диңгездә синнән башка да җанварлар күп! Алар синең кебек тиле бакаларны диңгезгә төшеп җитмәс борын ук кабып йотачаклар! — дигән елга.

Шулай дигән дә баканы калдырып әллә кая агып та киткән.

Шуннан соң бака яр читендә елап җибәргән. Шул чагында тагын бер болыт килгән дә яңгыр булып бака янындагы бер чокырны су белән тутырган. Бака тәпиләрен чәбәкләгән.

— Күлем үземә кайтты! Кире үземә кайтты! — дип куанган.

Тик ул арада кояш чыккан да, күлләвекне парга әйләндереп, тагын болытка иярткән.

Бака-бакылдык тычкан дусты янына барган да үзенең кайгысын сөйләгән.

— Күлемне яңа гына тапкан идем, тагын болыт алып китте,— дигән.

Тычкан әйткән:

— Бер дә кайгырма, хәзер көз җитте, яңгырлар да явар, күлләвекләр дә күбәер. Тик сиңа хәзер күлләвекләр турында түгел, ә корыда кыш чыгу турында уйларга кирәк булыр,— дигән.

Чыннан да, көзге яңгырлар көне-төне яуган, тирә-якны күлләвекләр каплаган, әмма кайсына гына карамасын, барысы да салкын икән. Шуннан соң бака кыш чыгар өчен тычкан оясына үзенә урын түшәгән. Ә үзе:

— Яз гына җитсен, болытка ияреп күлем генә кайтсын, койрыгыннан шәпләп тотармын да, бүтән беркая да җибәрмәм,— дип уйлаган.

Тик икенче җәйне дә болытның койрыгын тота алмаган.

Әнә шулай бака-бакылдык гомере буена хыяллана икән.



# ЭЧТӘЛЕК


Куян көчтәнәче . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
Әле ярый, айны тишмәде . . . . . . . . . . . . . 5
Аю баласы белән керпе . . . . . . . . . . . . . 8
Татлы җәймә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
Сабак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Кар бабай кая киткән? . . . . . . . . . . . . . 13
Шук йомгак . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Акыллы куян . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Зурколак белән телефон . . . . . . . . . . . . 19
Нечкәбил белән аю . . . . . . . . . . . . . . . 22
Бабай түбәтәе . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
Зурколак белән һава шары . . . . . . . . . . . 24
Мактанчык чыпчык . . . . . . . . . . . . . . . 26
Кавын . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 27
Шифалы сөт . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28
Шук карлыгач . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
Тылсымлы башмаклар . . . . . . . . . . . . . . 32
Тәгәрмәч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Кабак һәм аның дуслары . . . . . . . . . . . . 35
Ботка нигә тәмле? . . . . . . . . . . . . . . . 41
Таган балалаган . . . . . . . . . . . . . . . . 43
Болытның койрыгы кайда? . . . . . . . . . . . . 49




Издание для детей и юношества

**Саубанова** Самига Агельтдиновна

***ГДЕ ХВОСТ У ОБЛАКА?***

Сказки

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректоры *Л.Ш.Шәфыйкова*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 22.09.2003. Форматы 70×100 1/16. Офсет кәгазе. "Школьная" гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 4,55. Шартлы буяу-оттиск 19,50. Нәшер-хисап табагы 2,70. Тиражы 3000 данә. Заказ Я-632.

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.
http://tatkniga.ru
e-mail: tki@tatkniga.ru

"Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.

*Кадерле укучыбыз!*

Татарстан китап нәшрияты 2004 елда түбәндәге китапларны бастырып чыгарачак:

Шәриф Камал
САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

Галиәсгар Камал
САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

Фатих Кәрим
КЫР КАЗЫ

Сафа Сабиров
АЛТЫН БАЛДАКЛЫ АБЫСТАЙ

Мәгъсум Хуҗин
ИРТӘНГЕ ЯҢГЫР

Факил Сафин
САТАШЫП АТКАН ТАҢ

Данил Салихов
МӨГЕЗ

Мөсәгыйть Хәбибуллин
АЙБИБИ

